**IV ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕРЭШ-ШУРАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ Х УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 17**

**Керэш-Шуран** **17 май 2021 ел**

**«Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәсен оештыру тәртибе турында» 2015 елның 15 июнендәге 83 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236 номерлы Россия Федерациясе Законы, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге территориаль иҗтимагый үзидарәсен оештыру тәртибе турында» 2015 елның 15 июнендәге 83 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керэш-Шуран авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

– 14 статьяның 14.4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) инициативалы проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Керэш-Шуран авыл җирлеге башлыгы:** **Р.Г.Сафиуллин**